СОВЕТ КЛЯУШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Октябрьская, д.16, д.Пойкино,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422142

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЕЛӘҮШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Октябрь ур., 16 нче йорт, Пойкино авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422142

тел.(факс): (85563) 3-89-193; e-mail: Kls.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение | Карар

14 ноябрь 2018 ел | № 2-26

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Келәүш авыл җирлегенең 2016 елның 3 мартындагы 1-7 карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Келәүш авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 26 июлендәге 192-ФЗ номерлы федераль законнар, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 8 һәм 25 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 05 июлендәге 45-ТРЗ номерлы, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 19 июлендәге 55-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Келәүш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы, Мамадыш районы прокурорының 2017 елның 15 сентябрендәге 1-7 номерлы Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Келәүш авыл җирлеге Советы карарының аерым нигезләмәләренә карата №02-08-02-17 протесты нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Келәүш авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Келәүш авыл җирлегенең 2016 елның 3 мартындагы 1-7 карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Келәүш авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 7.1. пунктының 10 пунктчасына “- күрсәтелгән бәяләмәгә шикаять белдерү өчен билгеләнгән срок тәмамланган көннән алып 10 ел эчендә Россия Федерациясенең тиешле субъекты чакыру комиссиясенә, ә күрсәтелгән бәяләмә һәм (яисә) Россия Федерациясенең тиешле субъекты чакыру комиссиясе карарына карата гражданның күрсәтелгән бәяләмәсенә карата шикаять белдерелгән булса, - суд карары законлы көченә кергән көннән алып 10 ел эчендә, ул күрсәтелгән бәяләмәне чыгарганда һәм (яисә) гражданның

күрсәтелгән бәяләмәгә шикаяте буенча Россия Федерациясе субъектының тиешле комиссиясе карарын карар чыгарганда гражданның хокуклары бозылмаган дип танылган".

1.2. 11.10. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11.10. Контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм күрсәтелгән вазыйфаны биләүче зат үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында Татарстан Республикасы законында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Президентына белешмәләр тапшыра.»

1.3. 11.12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11.12. 11.10 пункты нигезендә тапшырыла торган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Президенты карары буенча гамәлгә ашырыла.».

1.4. 11.13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11.13. 11.12 пункты нигезендә гамәлгә ашырылган тикшерү нәтиҗәсендә контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затның "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" Федераль закон, 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, "Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә башка затлар чыгымнарының туры килүен тикшереп тору турында" 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, "Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булдыруны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларыннан файдалануны тыю турында" 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә үтәлмәве фактлары ачыкланганда, Татарстан Республикасы Президенты контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затның вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турындагы яисә аны тиешле карарны кабул итәргә вәкаләтле җирле үзидарә органына башка дисциплинар түләтүгә карата куллану турындагы гариза белән яисә судка мөрәҗәгать итә.».

1.5. 13.2.пунктка түбәндәге эчтәлектәге «е» пунктчасы өстәргә:

« е) муниципаль хезмәт вазыйфаларына муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече һәм өлкән төркемнәренә карый торган вазыйфалар биләгәндә.»

1.6. 16.4. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16.4. Ел саен өстәмә түләүле яллар муниципаль хезмәткәргә тиешле еллар эшләгән өчен, шулай ук федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган очракларда бирелә. Тиешле еллар эшләгән өчен муниципаль хезмәткәргә еллык өстәмә түләүле отпускның дәвамлылыгы муниципаль хезмәтнең һәр елы өчен бер календарь көн исәбеннән исәпләнә.

Еллык төп түләүле отпускның һәм тиешле еллар эшләгән өчен еллык өстәмә түләүле отпускның гомуми дәвамлылыгы 40 календарь көннән арта алмый. Нормалаштырылмаган хезмәт көне билгеләнгән муниципаль хезмәткәргә нормалаштырылмаган хезмәт көне дәвамлылыгы өч календарь көнгә тигез еллык өстәмә түләүле отпуск бирелә.

Нормалаштырылмаган хезмәт көне өчен еллык өстәмә түләүле отпуск, шулай ук федераль законда каралган башка очракларда бирелә торган еллык өстәмә түләүле отпуск ел саен төп түләүле отпускның һәм тиешле еллар эшләгән өчен еллык түләүле өстәмә отпуск әлеге өлешендә каралган дәвамлылыктан тыш бирелә.».

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында mamadysh.tatarstan.ru, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырып бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Мамадыш муниципаль районы Келәүш авыл җирлеге башлыгы Б.В.Ивановка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Келәүш авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе — Б.В.Иванов

Совет Кляушского сельского поселения
Республика Татарстан Муниципальное образование «Кляушское сельское поселение» Мамадышского муниципального района
ИНН 1626001066